ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

# КАРАР

«15» апрель 2019 ел №302

**Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 29 октябрендәге 822 номерлы "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында финанс-бюджет өлкәсендә контрольлек итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру Тәртипләрен раслау турында" карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 29 октябрендәге 822 номерлы "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында финанс-бюджет өлкәсендә контрольлек итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру Тәртипләрен раслау турында" карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1)1 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

2) эчке муниципаль финанс контроле органы тарафыннан финанс-бюджет өлкәсендә контрольлек итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру Тәртибендә (2 нче кушымта):

-8 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

-10-11 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Әлеге Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи затларның хокуклары:

а) контроль объектыннан ревизияләр һәм тикшерүләр үткәрү өчен (алга таба-контроль чаралар) дәлилләнгән сорату нигезендә кирәкле мәгълүмат, документлар һәм материаллар, шулай ук аларның күчермәләрен язмача яки телдән сорарга һәм алырга;

б) контроль объектыннан контроль чараларын уздыру өчен кирәкле аңлатмаларны язмача яки телдән алырга;

в) күчмә тикшерүләр (ревизияләр) барышында шәхесне таныклаучы документ (хезмәт таныклыгы) күрсәтеп һәм контроль чара үткәрү турында контроль органының хокукый актының күчермәләре нигезендә контроль чарасы үткәрелә торган биналарга һәм территорияләргә тоткарлыксыз узу, җитештерелгән товарларны күрсәтүне, башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләрнең нәтиҗәләрен таләп итәргә;

г) бәйсез экспертлар (махсуслаштырылган эксперт оешмалары);

башка дәүләт органнары белгечләре;

тикшерү органнары карамагындагы учреждениеләр белгечләре чакырып, фото -, видео - һәм аудиотехника, шулай ук башка төр техника һәм приборлар, шул исәптән үлчәү приборлары кулланып, контроль чаралар үткәрү өчен кирәкле экспертизалар билгеләргә (оештырырга);

Бәйсез эксперт (махсуслаштырылган эксперт оешмасы) дип контроль чарасы нәтиҗәсе белән кызыксынмаган, махсус белеме, тәҗрибәсе, квалификациясе булган, контракт (килешү) нигезендә экспертиза үткәрүче физик зат (юридик зат) аңлашыла;

башка дәүләт органы белгече дип дәүләт хакимияте органының тиешле җитәкчесе белән килешү буенча контроль чаралар үткәрүгә җәлеп ителүче Федераль дәүләт хакимияте органы, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органы дәүләт хезмәткәре аңлашыла;

контроль органы карамагындагы учреждение белгече дип контроль органы җитәкчесе (җитәкчесе урынбасары) йөкләмәсе нигезендә тикшерү чарасын үткәрүгә җәлеп ителә торган контроль органы функциясен һәм вәкаләтләрен башкаручы казна, бюджет, автоном учреждение хезмәткәре аңлашыла;

д) эчке дәүләт (муниципаль) финанс контролен гамәлгә ашыру өчен мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында Россия Федерациясе законнарын, дәүләт һәм башка законнар белән саклана торган сер турында Россия Федерациясе законнарын үтәп, дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларыннан, контроль объекты хуҗасы яки операторы булган мәгълүмат системаларыннан файдалану мөмкинлеге алырга;

е) контроль объекты эшчәнлеген документаль һәм (яки) фактик өйрәнү буенча чаралар үткәрергә (оештырырга), шул исәптән тикшерү, инвентаризация, күзәтү, яңадан исәпләү, экспертиза, тикшеренүләр, контроль үлчәүләр юлы белән дә.

11. Әлеге Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи затларның бурычлары:

а) Россия Федерациясе бюджет законнары һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган башка хокукый актлар нигезендә эчке дәүләт (муниципаль) финанс контролен гамәлгә ашыру буенча контроль органы вәкаләтләрен үз вакытында һәм тулысынча үтәргә;

б) контроль чаралар үткәрелә торган контроль объектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен сакларга;

в) контроль чараларны контроль органының контроль чаралар үткәрү турындагы хокукый акты нигезендә үткәрергә, кирәк булганда, контроль чара үткәрү турында контроль органы хокукый актының күчермәсен күрсәтергә;

г) контроль чарасы үткәргәндә контроль объекты эшчәнлеген гамәлгә ашыруга комачаулауга юнәлдерелгән гамәлләр кылмаска;

д) контроль объекты җитәкчесен (вәкилен) контроль органының тикшерү чарасын үткәрүне туктатып тору, яңарту һәм озайту турында, тикшерү (ревизия) төркеме составын үзгәртү турында хокукый акт күчермәсе белән, контроль чараларының нәтиҗәләре белән (актлар, бәяләмәләр) таныштырырга;

е) контроль объектының җитәкчесенә, вазыйфаи затына яисә бүтән хезмәткәренә күчмә тикшерү (ревизия) барышында контроль объекты эшчәнлеген фактта өйрәнү (карау, инвентаризацияләү, күзәтү, яңадан санау, экспертиза, тикшерү, контроль үлчәү) буенча контроль чаралар үткәргәндә катнашу һәм контроль чарасы предметына караган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә комачауламаска;

ж) Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган очракларда ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр, тәкъдимнәр җибәрергә;

з) Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган очракларда бюджет чаралары куллану мәҗбүрилеге турында хәбәрнамәләр җибәрергә;

и) административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча эшләрне гамәлгә ашырырга;

к) гавами-хокукый берәмлеккә зыянны каплау, Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда сатып алуларны гамәлдә түгел дип тану турында дәгъва гаризалары белән судка мөрәҗәгать итәргә;

л) җинаять составы билгеләре булган гамәлләр кылу факты ачыклану турында мәгълүматны һәм (яки) әлеге фактны раслый торган документларны һәм башка материалланы хокук саклау органнарына җибәрергә;

м) әлеге орган (вазыйфаи зат) компетенциясенә караган хокук бозу билгеләре булган хәлләрне һәм фактларны ачыклый торган мәгълүматны һәм (яисә) әлеге фактларны раслый торган документларны һәм башка материалларны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә дәүләт органы (вазыйфаи зат) адресына җибәрергә.»;

- 36 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«36. Тикшерү нәтиҗәләре буенча әзерләнгән бәяләмәне карау нәтиҗәләре буенча, әгәр ул хокук бозу билгеләре булу-булмауңы күрсәтә торган мәгълүматны үз эченә алган булса, Җитәкче планнан тыш күчмә тикшерү (ревизия) үткәрүне билгели.»

- 54 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«54. Тикшерү (ревизия) үткәрү тикшерү (ревизия) төркеме җитәкчесенең дәлилләнгән мөрәҗәгате нигезендә Җитәкче тарафыннан туктатыла:».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарылырга һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) халыкка җиткерелергә тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р.Мөхәрәмовка йөкләргә.

Җитәкче И.Ә. Галимуллин